

## НӘРСӘ ЭЧӘБЕЗ?

«ВТ» хәбәрчесе Казандагы суның сыйфатын ачыклады

> 7



## ЯЗМЫШТАН УЗМЫШ

Тормышны үзгәртү өчен сан һәм картага гына карау җитәме?

> 15



## АЛСУ ГАЙНУЛЛИНА:

«Минем өчен гаилә һәрвакыт беренче урында булды»

> 18


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 4 (28971) | Җомга | 13 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131




Илдар Мөхәммәтҗанов

# ТОРМЫШ БӘЯСЕ

## ЯҢА ТАРИФЛАР ХАЛЫКНЫ ПОШАМАНГА САЛДЫ

**Көн кадагындагы мәзәк: «Коммуналь түләү кәгазьләренә караганда, хәзер краннан чишмә суы ага, ә чүпне «Лексус» машинасында чыгаралар...» Тик моңа көләргә дә, еларга да белмәссең. Ел башы «тешли» торган коммуналь түләү кәгазьләре белән истә калыр, мөгаен. Тик бу көтмәгәндә килеп чыккан хәл түгел. Ут-суга бәяләр артачагы турында былтыр ук кисәттеләр. Белгечләр хис белән түгел, ә акыл белән эш итәргә куша. Декабрь өчен коммуналь түләү кәгазен «ВТ» хәбәрчесе дә җентекләп өйрәнде.**

> 5

### Ишетми калмагыз

Узган елның гыйнварыннан ноябрьгә кадәр Татарстанның нефть эшкәртү компанияләре 2,6 миллион тоннадан артыграк бензин эшләп чыгарган. Бу – алдагы елдагыга караганда 43 процентка күбрәк. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, дизель ягулыгын җитештерү 10,3 миллион тоннага җиткән.
Тулаем алганда, Татарстанда шушы чорда барлыгы 20,4 миллион тонна нефть (2021 елның шушы ук чорындагыга караганда 13 процентка күбрәк) эшкәртелгән.

Былтыр Россиядә сатылган транспорт саны алдагы ел белән чагыштырганда 55 процентка кимегән. Бу хакта «Автостат» аналитика агентлыгының башкарма директоры Сергей Удалов әйткән. Җиңел автомобильләр – 59, җиңел коммерция транспорты – 48, йөк машиналары – 16, автобуслар исә 7 процентка азрак сатылган.

Казанның Идел буе районындагы 2 нче Газ урамы атаклы эшмәкәр һәм Татарстаннан Дәүләт Думасы депутаты булган Айрат Хәйруллин исемен йөртәчәк. Урамдагы йортларның адрес номерлары сакланып кала. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Гаффаров бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган. Карар шәһәр документлары һәм хокукый актларының махсус чыгарылышында басылып чыккан.
Айрат Хәйруллинның гомере 2020 елның 7 февралендә вертолет һәлакәтендә өзелде. Аңа 49 яшь иде.

Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марат Сафиуллин «Рубин» футбол клубының президенты итеп билгеләнде. Бу хакта Казан клубының матбугат хезмәте хәбәр итте. Директор вазыйфасын күп еллар «Ак барс»та эшләгән Шамил Хөснетдинов башкарачак. Моңа кадәр генераль директор булып эшләгән Рөстәм Сәйманов исә клубтан китте. Билгеле булганча, узган ел Казан командасы үз тарихында тәүге мәртәбә премьер-лигадан төшеп калды. Декабрьдә исә баш тренер Леонид Слуцкий да вазыйфасыннан китте, аның урынына Юрий Уткульбаевны билгеләделәр.

Зәмһәрир суыклар чигенә. Ял көннәрендә Татарстанда көндез –14, төнлә –19 градус көтелә. Республика Гидрометеоүзәге мәгълүматларына караганда, якын араларда Татарстанда явым-төшем көтелми. Шимбә, якшәмбе – 14–15 гыйнварда термометрның терекөмеш баганасы көндез –8...–14, төнлә –12...–19 градус күрсәтәчәк. Киләсе атна башында һава температурасының көндез –7...–12, төнлә –12...–17 градус чикләрендә тирбәлүе фаразлана.
Республикада гыйнварның беренче декадасында тәүлеклек уртача температура нормадан 13–23 градуска кимрәк булган. Атна башында – 9 һәм 10 гыйнварда Баулы, Мөслим метеостанцияләрендә һава температурасының 40 градустан түбәнрәк төшүе теркәлгән.

# ТОРМЫШ БӘЯСЕ


vk.com

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Узган елның 1 декабреннән ил күләмендә коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр күтәрелде. «Очрашу өчен бик күңелле сәбәп түгел. Тарифларны арттыруның чираттагысы киләсе елның 1 июлендә генә көтелсә дә, ә бәяләр гадәттә елга бер тапкыр үсә, ил Хөкүмәте карары нигезендә әлеге чара 2022 елның 1 декабренә күчерелде. Шул рәвешле, бер ел эчендә икенче тапкыр коммуналь хезмәтләргә бәяләр артты», – диде узган ел ахырында тарифлар үсүгә багышланган чарада Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев.

Гыйнвар башында әнә шул яңача исәпләнгән коммуналь түләү кәгазьләре килде дә инде. Без хәзер ут, газ, җылылык, су, пычрак суларны агызу һәм каты көнкүреш калдыкларын чыгару өчен кыйммәтрәк түлибез. 1 декабрьдән республика күләмендә бәяләр уртача 9 процентка артты. Бер ел эчендә коммуналь хезмәтләргә бәяне ике тапкыр арттыруның сәбәбе дә билгеле: республикадагы инженер челтәрләренең өчтән бере тузган. Татарстанда 5900 чакрым озынлыкта су үткәрү, 1 мең чакрымнан артык озынлыкта җылылык челтәрен алмаштырырга кирәк. Кыскасы, ут янсын, су аксын өчен күбрәк түләргә туры киләчәк. Александр Груничев тынычландырырга да ашыкты: моннан ары коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 2024 елның җәендә генә артачак. Тик саннар – бер, чынбарлык икенчерәк булып чыкты. Гыйнвар түләвен кулга алучылар чак кына артына утырмады.

## Президент та белә

Иң кызу бәхәс интернетта купты. Чаллы халкы, ут-суга бәяләр чамадан тыш артык кыйммәтләнүгә ачыклык кертүләрен сорап, петициягә имза да җыя башлады хәтта. Әлеге хатны сигез меңгә якын кеше имзалаган инде. Социаль челтәрләрдә дә шау-шу дәвам итә. «Ноябрьдә 53 квадрат метрлы ике бүлмәле фатир өчен 4685 сум акча түләгән идем. Декабрь өчен 6 мең сумнан артык акча исәпләгәннәр. Вәгъдә ителгән 9 процент кыйммәтләнү кайда соң?» – дип язган Зәйдән Алинә Гобәйдуллина. «Ноябрьдә 1 Гкалл җылылык өчен 1920 сум түли идек, декабрьдә исә әлеге төр түләү 2093 сумга җиткән. Ярар, шулай булсын, ди. Ә җылылык өчен түләү ник 1910 сумнан 3820 сумга кадәр җиткән соң?» – дип зарланган Яшел Үзәннән Марат Вафин.

Республикада яшәүчеләрнең аһ-зарын Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та ишеткән. Бу дүшәмбедә Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә ул коммуналь хезмәтләр өчен яңа бәяләргә бәйле шикаятьләр буенча тикшерү үткәрергә һәм халыкка тарифлар артуның сәбәпләрен аңлатырга кушты.

> Республика халкы декабрь аена яңа тарифлар буенча квитанцияләр ала башлады. Татарстан Төзелеш министрлыгына, район администрациясе башлыкларына һәм тиешле оешма җитәкчеләренә исәпләүләрнең дөреслеген тәэмин итәргә кушам. Барлык шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр буенча тикшерү оештырыгыз. Халыкка түләү сәбәпләрен аңлату, шулай ук республикада гамәлдә булган социаль ярдәм чаралары турында сөйләү мөһим, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына субсидияләрне вакытында түләүне тәэмин итәргә дә кушты.

## Акча санаганны ярата

«ВТ» хәбәрчесенә бу айда 72 квадрат метрлы фатир өчен 9354 сумлык түләү кәгазе килде. Чагыштыру өчен, ноябрьдә түләү күләме 7214 сум тәшкил иткән. Декабрь өчен түләүнең шактый өлеше, тәгаен әйтсәк, 4222 сумы җылылыкка туры килә. Төп башына утыртканнармы әллә? Белгечләр исә, болай фикер йөртү дөрес түгел, ди.

– Ноябрь, декабрьдә һава торышы төрле. Шуңа күрә җылылык та төрлечә исәпләнә. Шул ук ут, кайнар суны тоту күләме дә айдан-айга аерыла. Шуңа күрә, узган айда азрак түләгәнмен, дип фикер йөртүчеләр ялгыша. Коммуналь түләү кәгазьләрен якынча чагыштырган очракта да, аны һич югы узган елның шушы ук чоры белән тәңгәлләштереп карарга кирәк, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин.

Аңлатма бирүләрен сорап, идарәче оешмага да шалтыраттык. Алар исә бу көннәрдә халыктан килеп ирешкән шикаятьләр күп булуына ишарәләп, язмача мөрәҗәгать итәргә киңәш иттеләр. «Кемгә күпме акча исәпләнүен ике сүз белән генә аңлатып булмый. Мәсәлән, җылылык күпме тотылганны белү өчен күпкатлы йортка кергән җирдә куелган исәпләгеч күрсәткечләрен алырга, аны мәйданына карап, фатирларга, гомуми кулланылыштагы урыннарга бүләргә, торак һәм торак булмаган бүлмәләрне аерырга кирәк. Барысын да аңлатып бирербез», – диделәр телефонның теге очында.

– Яңа бәяләр турында сөйләгәндә, былтыр тарифларның бер ел эчендә ике тапкыр артуын да истә тотарга кирәк, – ди Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе урынбасары Светлана Заһидуллина. – Билгеле булганча, 1 июльдән республикада коммуналь хезмәтләргә бәяләр уртача 6,7 процентка кыйммәтләнде. Башкалада, мәсәлән, әлеге күрсәткеч 13 процентка җитте. Шуңа күрә узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, хәзер бәяләр 20 процентка кадәр кыйммәтрәк. Әнә шул үзен сиздерде дә инде.

«ВТ» хәбәрчесенең түләүләренә әйләнеп кайтсак, узган елның декабре өчен ул 8186 сум тәшкил иткән. Быелгысы белән чагыштырып карасаң, аерма 20 проценттан да кимрәк чыга. Исәпләүләр дөрес түгел дип уйларга җирлек юк, димәк.

## 2 миллион сум кайтарганнар

Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев әйтүенчә, түләү кәгазен кулга алгач та, иң элек кулланылган ут-су күләменә игътибар итәргә кирәк.

– Артык акча исәпләмәсеннәр дисәгез, ут-суга куелган исәпләгеч җайланмаларның күрсәткечләрен вакытында тапшырыгыз. Тарифларга бәйле сораулар туса, (843) 236-36-36 телефон номеры буенча Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетының «кайнар линия»сенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты, аларның вакытында күрсәтелмәве яки исәпләүләргә бәйле шикаятьләр булган очракта, иң элек коммуналь хезмәтләр күрсәтүчегә, ягъни идарәче компания, торак хуҗалыгы ширкәтенә, ә алардан тиешле җавап булмаса яки ул канәгатьләндермәсә, Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итә аласыз, – ди Александр Груничев.

Халыктан килеп ирешкән барлык шикаятьләр ныклап тикшереләчәк, дип ышандырдылар Татарстан Дәүләт торак инспекциясендә.

– Без кулланучыларның хокуклары бозылырга мөмкин дип тапкан очракта тикшерү эше башлый алабыз. Хәзер исә безгә бер-ике җөмлә белән генә коммуналь хезмәтләр өчен бик күп исәпләгәннәр, дип язалар. Тик монда хокук бозу факты юк. Шунысын да әйтик: соңгы арада халык арасында бу мәсьәләгә бәйле ризасызлык зур булуын аңлап, без һәр очрак буенча идарәче оешмалардан аңлатма бирүләрен сорыйбыз. Тик бу гына тикшерү башларга сәбәп була алмый. Шуңа күрә тагын бер кат искәртәбез: коммуналь хезмәтләрдән риза булмаучылар, аңлатма бирүләрен сорап, иң элек әлеге төр хезмәтне күрсәтүче оешмага барырга тиеш. Идарәче оешма җавап бирмәсә яки ул җавап канәгатьләндермәсә, Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итә аласыз. Безгә язган хатта идарәче оешмадан алган җавапны да беркетергә онытмагыз, – ди Светлана Заһидуллина.

11 гыйнварга алынган мәгълүматларга караганда, Татарстан Дәүләт торак инспекциясенә, коммуналь хезмәтләр өчен яңа бәяләрдән ризасызлык белдереп, 85 кеше мөрәҗәгать иткән инде. Узган ел милек хуҗаларына коммуналь түләү кәгазьләрендә арттырып күрсәтелгән 2 миллион сумнан артык акчаны кайтарганнар.

## Районнарда ничек?

Чаллы Башкарма комитеты җитәкчесе Фәрит Сәләхов сүзләренә караганда, шәһәрдә җылылык өчен тариф – республика күләмендә иң түбән күрсәткечләрнең берсе.

– Әйтик, Зәйдә 1 Гкал җылылык энергиясе бәясе 2367 сум тәшкил итә, Түбән Камада ул – 2158 сум, Казанда исә 2136 сум тора. Автокалада әлеге тариф – 2093 сум. Татарстанның башка районнары белән чагыштырганда, Чаллыда тарифлар артык югары түгел. Җылылык челтәрләренең куллану вакыты – 20 ел. Димәк, бер елда аларның 5 процентын төзекләндерү зарур. Әгәр акча җитмәсә, әйтик, аларның 2 процентын гына төзекләндерәчәкбез. Ә калган 3 проценты шулай калачак һәм вакыты чыккан килеш эшләячәк. Бу исә аварияләргә китерергә мөмкин, – дип сөйләгән шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе журналистларга.

Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Роман Булатов әйтүенчә, тарифларны арттырмыйча да булмый. «Әлеге карар федераль дәрәҗәдә кабул ителде. Түбән Камада тарифларны арттыруны урынында карап тикшердек. Бәяләрне арттыруның сәбәпләре дә аңлашыла. Мәсәлән, «Водоканал» насосы электр ярдәмендә эшли, ә аны сатып алырга кирәк. Электр эшләп чыгаручы ТЭЦ исә газ сатып алырга мәҗбүр. Барысы да үзара бәйләнгән. Әгәр коммуналь хезмәтләр өчен акчаны дөрес исәпләмәгәннәр дип санайсыз икән, иң элек идарәче оешмага мөрәҗәгать итәргә кирәк. Кулланучы буларак, үз хокукларыгызны яклый белергә кирәк. Бу – дөрес юл, тик кайбер очракта бик җиңел түгел», – дип китергәннәр җитәкче сүзләрен районның рәсми сайтында. Башыңа төшсә, башмакчы буласың, дип юкка гына әйтмиләр шул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

### КОММУНАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР ӨЧЕН ТҮЛӘҮДӘ СУБСИДИЯ КЕМНӘРГӘ ТИЕШ?

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә социаль ярдәм чараларының тулы бер комплексы гамәлдә. Федераль ташламага ия булучылар, ягъни Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, инвалид бала тәрбияләүче гаиләләр мондый хокуктан файдалана ала. Төбәк дәрәҗәсендә ташламага ия булучыларга хезмәт ветераннары, реабилитацияләнгән, репрессияләнгән гражданнар һәм күпбалалы гаиләләр керә. Андыйларга ташлама күләме, ярдәм чараларын алучыларның категориясенә карап, 30–50 процент тәшкил итә.
РФ Торак кодексының 159 нчы маддәсе нигезендә, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә бәйле чыгымнар гаиләнең уртак кеременең билгеле бер чигеннән артып китсә, ә Татарстанда әлеге күрсәткеч 21 процент тәшкил итә, әлеге гаилә аз керемле булып санала һәм шулай ук субсидиягә өмет итә ала.
Субсидияне Дәүләт хезмәтләре порталы аша да рәсмиләштереп була. Бүген социаль ярдәм чаралары алучыларның 90 проценты документларны өйдән чыкмыйча гына тапшыра. Социаль яклау органына барган очракта, паспорт һәм исәп-хисап счеты кирәк. Калган мәгълүматны белгечләр үзләре туплаячак.
Татарстанда субсидиянең уртача күләме 900 сумнан 1 мең 200 сумга кадәр тәшкил итә. Бүген Татарстанда 270 мең кеше – федераль ташламалардан, тагын 370 мең кеше төбәк дәрәҗәсендәге ташламалардан файдалана.